# Г. Тукай асарларенең тел - стиль узенчалекларе

# Фәнни – тикшеренү эшенең максаты:

- **Г.Тукайның татар әдәби телен халык теленә якынайту өлкәсендәге эшчәнлеген** өйрәнү;
- **Г.Тукай татар теленең сүзлек хәзинәсе белән оста эш итә** алуын ачыклау**;**
- **Г. Тукай чагыштыруларның төрле формаларын оста куллануны тикшерү.**



# Габдулла Тукай

1886 - 1913

Полисемия күренеше Тукай өчен аеруча характерлы. Мәсәлән:

*Җаннарым, күз нурларым, сез, бу мәһабәтне күреп,*
*Җан ачып, "во как!" дисез, мазлум мужиклар семьясы*,-
("Сайфия".)

дигән өзектә *семья* сүзе тар мәгънәсендә *гаилә* сүзенең синонимы гына түгел, бәлки бер сыйнфый төркемне, хезмәт иясе массасын белдерү өчен. китерелгән

Диалекталь сүзләр:

-Китте кушкан җиргә, атлап адымын *ире-ире* („Шүрәле");

-кайда *баксаң, анда* тулган сәүдәгәр („Печән базары...");

Гарәп-фарсы сүзләренең кайберләре вакытлар үтү белән архаик формага әйләнгән *тәрәкъкый* (прогресс), *җәһаләт* (наданлык), *тәгассеп* ( фанатизм), *сәнә* (ел), *важҗыптыр* (тиештер), *сәма* (күк), *мәдәт* (ярдәм), *карья* (авыл), *гасый* (гөнаһлы), *зольмәт* (караңгылык), *икъбал* (якты, киләчәк).

Рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләр:
*закон, полиция, суд, юрист, адвокат, театр, билет, арсенал, бульвар,* һ.б.

Ижтимагый-политик төшенчәдә йөргән сүзләр:

*капитал, депутат, политика, конкуренция, бюрократ, локаут, мещан* һ.б.

Фразеологик әйтелмәләрне Г. Тукай бик актив куллана. Мәсәлән: *ут йоту, милли агачларга куну, күңелем кошы, күз ату, күкләрдән йолдыз чүпләү, мәкерләр капчыгы, сәгадәт талы, мәхәббәт кайчысы...*

Г. Тукай чагыштыруларның төрле формаларын оста куллана.

Мәсәлән: „*Ашап яткан сорыкортка кадалдым мисле хәнҗәр мин"*

(“Сорыкортларга”).

-*Кузгалып китте вагон, җилдәй бара"*.

-„*Ташбака төсле, вагон әкрен килә”*

(“Печән базары...”).

Сынландыру алымы да кулланыла:

Аглыйдыр һәркем, күзеннән яшь сыгып,
Аглый кибеттән кәләпүшләр чыгып.
һәм аяк астында яткан тиреләр
Барча: „Ай мескен!" дә, „ай мескен!"-диләр.

(„Печән базары...").


Игътибарыгыз өчен рәхмәт